**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

| | | |
|---|---|---|
| **ПРИКАЗ** | Казан ш. | **БОЕРЫК** |
| №950-п | | 01.09.2021 |

Татарстан Республикасы территориясендә табигать саклау законнары бозылуны теркәүдә ярдәм күрсәткән гражданнарга түләүләрне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы турындагы нигезләмәгә таянып, шулай ук экологик куркынычсызлык дәрәҗәсен арттыру һәм Татарстан Республикасында табигать саклау законнары бозылу очракларын ачыклау максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы территориясендә табигать саклау законнары бозылуны теркәүдә ярдәм күрсәткән гражданнарга түләүләрне гамәлгә ашыру тәртибен (кушымтада бирелә) расларга.

2. Дәүләт экологик күзәтчелек инспекциясе башлыгына әлеге боерык белән расланган Тәртипне Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составындагы рәсми сайтында, «Дәүләт экологик күзәтчелек» бүлегендә урнаштырырга.

3. Экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендәге проектларны пропагандалау бүлегенә Татарстан Республикасы территориясендә массакүләм мәгълүмат чараларында Татарстан Республикасы территориясендә табигать саклау законнары бозылуны теркәүдә ярдәм иткән өчен гражданнар тарафыннан түләүләр алу мөмкинлеге турында мәгълүмат яктыртуны оештырырга.

4. Финанс контроле, исәпкә алу һәм хисаплылык бүлегенә Татарстан Республикасы территориясендә табигать саклау законнары бозылуны теркәүдә ярдәм иткән өчен гражданнарга түләүне гамәлгә ашыруны һәм күрсәтелгән түләүләрне Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә исәпкә алуны оештырырга.

5. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары А.М.Шиһаповны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
2021 елның 01.09. №950-п боерыгы
белән расланды

**Татарстан Республикасы территориясендә табигать саклау законнары бозылуны теркәүдә ярдәм күрсәткән гражданнарга түләүләрне гамәлгә ашыру тәртибе**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1 Татарстан Республикасы территориясендә табигать саклау законнары бозылуны теркәүдә ярдәм күрсәткән гражданнарга түләүләрне гамәлгә ашыруның әлеге тәртибе (алга таба – Тәртип) Татарстан Республикасы территориясендә табигать саклау законнары бозылу очракларын теркәүдә ярдәм иткән гражданнарга түләү максатларын һәм тәртибен билгели.

1.2 Тәртип рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

1.3 Татарстан Республикасы территориясендә табигать саклау законнары бозылуны теркәүдә ярдәм иткән гражданнарга түләүләрне Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (алга таба – Министрлык) оештыра.

1.4 Түләүләр «2014-2021 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигый ресурсларын яңадан торгызу һәм куллану» дәүләт программасы кысаларында Министрлык тарафыннан каралган акчалар кысаларында Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла.

## II. Төп билгеләмәләр

2.1 Әлеге тәртип максатлары өчен, табигать саклау законнарын бозу дигәндә түбәндәге билгеләмәләр аңлана:

- җитештерү һәм куллану калдыкларын ташлау (әйләнә-тирә мохитне пычратуга китергән (каты, сыек) калдыкларны аңа бүлеп чыгару, ташлау);
- Татарстан Республикасы территориясендә калдыкларны санкциясез урнаштыру (урнаштыру өчен билгеләнмәгән территорияләрдә калдыклар урнаштыру);
- Татарстан Республикасы территориясендә җир асты байлыкларыннан лицензиясез файдалану (лицензияләүче орган тарафыннан бирелгән документ белән раслана торган әлеге эшчәнлек төрен юридик зат яисә шәхси эшкуар тарафыннан башкару хокукына махсус рөхсәттән башка гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару);
- җирләрне бозу (туфракның уңдырышлы катламын рөхсәтсез салдырып алу яки күчерү, туфракның уңдырышлы катламын юк итү, шулай ук кешеләрнең сәламәтлеге һәм әйләнә-тирә мохит өчен куркыныч матдәләр, җитештерү һәм

куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен бозу нәтиҗәсендә җирләрне бозу);

- гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектына һәм аның яр буе полосасына ирекле үтеп керә алуын чикләү.

2.2 Фотолар – табигать саклау законнарын бозу факты буенча фотога төшерү.

2.3 Видеоязма – табигать саклау законнарын бозу очракларын теләсә нинди төрдәге электрон чыганакта видеога яздыру.

2.4 Мөрәҗәгать итүче – Министрлыкка Татарстан Республикасы территория-сендә табигать саклау законнарын бозу турында фото һәм видеоязма теркәп, хәбәр иткән Россия Федерациясе гражданины.

2.5 Түләү – административ хокук бозу турында закон көченә кергән карар нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә табигать саклау законнарын бозуны теркәүдә ярдәм күрсәткән мөрәҗәгать итүчегә 1500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләү (физик затлар керемено салым өлешен алып калганнан соң).

## III. Табигать саклау законнары бозылуны теркәүдә ярдәм күрсәтү тәртибе

3.1 Табигать саклау законнарын бозуларны теркәүдә ярдәм күрсәтү гариза тәртибендә гамәлгә ашырыла.

3.2 Видеоязма теркәлгән гариза түбәндәгечә бирелергә мөмкин:

- әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасында күрсәтелгән адреслар буенча, Россия Федерациясе гражданины паспортын күрсәткән очракта, мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән;
- электрон почта буенча eco.signal@tatar.ru адресына;
- «Халык инспекторы» дәүләт мәгълүмат системасы аша;

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының интернет кабул итү системасына: http://eco.tatarstan.ru/rus/priem.htm.

## IV. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелә торган мәгълүматлар исемлеге

4.1 Гариза биргәндә мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәгеләрне шәхсән тапшырырга кирәк:

- билгеләнгән үрнәктәге гариза (2 нче кушымта);
- теләсә кайсы типтагы видеоязма яки фотосүрәт.

4.2 Электрон почта аша мөрәҗәгать иткәндә түбәндәгеләрне тапшырырга кирәк:

- фамилиясе, исеме, атасының исеме;
- почта адресы;
- кәрәзле телефон номеры;
- теләсә кайсы типтагы видеоязма яки фото.

4.3 Интернет-кабул итү системасы аша мөрәҗәгать иткәндә түбәндәгеләрне тапшырырга кирәк:

- интернет-кабул итү системасы битендә күрсәтелгән белешмәләр;
- теләсә кайсы типтагы видеоязма яки фотосүрәтләр.

## V. Видеоязмага /фотосүрәтләргә карата таләпләр

5.1 Видеоязмада/ фотосүрәттә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) Табигать саклау законнарын бозу мизгеле;

б) Хокук бозучыны тәңгәлләштерә торган дәлилләрнең берсе:

- табигать саклау законнарын бозу гамәлгә ашырыла торган автотранспорт чарасының укыла торган дәүләт теркәү билгесе яисә башка төрле тану билгеләре, мәсәлән, автотранспорт чарасын тәңгәлләштерү мөмкинлеген бирә торган язулар, рәсемнәр һ.б. (шартларга карап);

- табигать саклау законнарын боза торган кешенең фото-видеосүрәте;

- гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектына һәм аның яр буе полосасына ирекле үтеп керә алуын чикләү факты турында фото-видео.

в) Видеога яздыру/фотога төшерү датасы һәм вакыты.

## VI. Материалларны карау

6.1 Алынган материаллар законнарда билгеләнгән тәртиптә карала.

6.2 Видеоязма/ фотосүрәтләр әлеге Тәртипнең V бүлеге таләпләренә җавап бирми икән, мөрәҗәгать итүчегә видеоязма/ фотосүрәтләрнең билгеләнгән таләпләргә туры килмәве турында Министрлык тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә хәбәр ителә.

## VII. Түләү шартлары һәм тәртибе

7.1 Түләү табигать саклау законнарын бозу фактын раслаган очракта һәм гаепле затны административ (җинаять) җаваплылыкка тартканда һәм законнарда билгеләнгән тәртиптә карар (хөкем карары) законлы көченә кергән очракта гамәлгә ашырыла.

7.2 Түләү биш эш көне эчендә, тиешле лимитлар һәм гамәлгә ашырылган финанслау булганда, карар (хөкем карары) законлы көченә кергәннән соң, Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры исеменә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә баш дәүләт инспекторының хезмәт язуы нигезендә башкарыла, ул билгеләнгән тәртиптә финанс контроле, исәп һәм хисаплылык бүлегенә җиткерелә.

7.3 Түләү нал булмаган акча (банк картасы булган очракта) түләү юлы белән яисә турыдан-туры Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы кассасында түбәндәге адрес буенча башкарыла: Казан шәһәре, Павлюхин урамы, 75 йорт.

7.4 Мөрәҗәгать итүчегә телефон элемтәсе аша гаризада (мөрәҗәгатьтә) күрсәтелгән номерга, ул күрсәтелгән адрес (электрон почта адресы) буенча язмача (электрон) формада күрсәтелгән түләү турында хәбәр ителә.

7.5 Түләүне алу өчен кассада мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны күрсәтә:

Россия Федерациясе гражданины паспорты;

Салым түләүченең тәңгәллек номерын;

Индивидуаль шәхси счетның иминият номерын;

шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык.

7.6 Түләүләрне акчасыз күчерү юлы белән түләгән очракта, әлеге Тәртипнең 7.5 пунктында күрсәтелгән документлардан тыш, мөрәҗәгать итүче банк реквизитларын да теркәргә тиеш. Барлык документлар Министрлыкның документларны кабул иткән тиешле территориаль идарәсе җитәкчесе тарафыннан раслана.

7.7 Бер үк хокук бозу буенча түләүләр гаризаны беренче булып (вакыты / датасы буенча) җибәргән мөрәҗәгать итүчегә бер тапкыр гына гамәлгә ашырыла.

## VIII. Түләү алучыга карата таләпләр

8.1 Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә Министрлык түләүләрне гамәлгә ашыру өлешендә салым агенты булып тора һәм салым түләүчедән салым күләмен исәпләп чыгару, тотып калу һәм салымны физик затлар кеременә бюджетка күчерү бурычын үти.

8.2 Финанс елы тәмамланганнан соң аның язма гаризасы буенча түләү алучыга 2-НДФЛ формасы буенча белешмә бирелә.

1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының территориаль идарәләре**

| **Территориаль идарәләр** | **Районнар** | **Адрес** | **Телефон** |
|---|---|---|---|
| Үзәк территориаль идарә | Казан шәһәре,<br>Югары Ослан<br>Биектау<br>Зеленодольск<br>Лаеш<br>Питрәч | 420049, Казан шәһәре,<br>Павлюхин урамы, 75,<br>E-Mail:<br>Ctu.plan@tatar.ru | 8(843)267-68-32<br>267-68-33 |
| Идел аръягы территориаль идарәсе | Апас<br>Буа<br>Чүпрәле<br>Кайбыч<br>Кама Тамагы<br>Тәтеш | 422430, Буа шәһәре,<br>Р. Люксембург урамы,<br>159/1,<br>E-Mail:zvtu@bk.ru | 8(84374)3-11-02,<br>3-57-28 |
| Төньяк территориаль идарә | Арча<br>Әтнә<br>Балтач<br>Кукмара<br>Саба<br>Теләче | 422000, Арча шәһәре,<br>Интернациональная урамы, 41,<br>E-Mail:sevtu@mail.ru | 8(84366)3-21-61 |
| Кама аръягы территориаль идарәсе | Зәй<br>Түбән Кама<br>Сарман | 423552,<br>Түбән Кама шәһәре,<br>Красный ключ районы, Набережная урамы, 7,<br>E-mail:<br>zakamtu@mail.ru | 8(8555)45-66-55 |
| Кама яны территориаль идарәсе | Әгерже<br>Актаныш<br>Алабуга<br>Мамадыш<br>Менделеевск<br>Минзәлә<br>Тукай<br>Чаллы шәһәре | 423838,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 64,<br>E-mail:<br>prirodart@mail.ru | 8(8552)59-36-39 |
| Ык буе территориаль | Азнакай<br>Баулы | 423330. Азнакай шәһәре, | 8(85592)5-15-48 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| идарәсе | Мөслим<br>Ютазы | Шоссейная урамы, 6,<br>E-mail:<br>eco.azn@mail.ru | |
| Көньяк-Көнчыгыш территориаль идарә | Әлмәт<br>Бөгелмә<br>Лениногорск<br>Нурлат<br>Чирмешән | 423450,<br>Әлмәт шәһәре,<br>Әминов урамы, 9 а,<br>E-mail:<br>uvgri@tatais.ru | 8(8553)33-03-25 |
| Идел-Кама территориаль идарәсе | Аксубай<br>Алексеевск<br>Әлки<br>Яңа Чишмә<br>Спас<br>Чистай<br>Балык Бистәсе | 422980, Чистай шәһәре,<br>Фрунзе урамы, 97 а,<br>E-Mail:vktu@mail.ru | 8(84342)5-35-19 |

2 нче кушымта

**Административ хокук бозу турында гариза**

Фамилия, исем, ата исеме (тулысынча)______________________________

_____________________________________________________________________

Почта адресы_________________________________________________________

__________________________________________________________________

E-mail_________________________________________________________________

Элемтә өчен телефон_____________________________________________________

Административ хокук бозуның координатасыы булган очракта, аның датасы, вакыты, урыны

_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_______________________________________________________
_____________________________________________________________________

Транспорт чарасының тибы, маркасы, дәүләт теркәү билгеләре_____________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_
_____________________________________________________________________

Административ хокук бозу вакыйгасының кыскача тасвирламасы_____________________________________________________________
_____________________________________________________________________
__________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________